| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ МОНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ МОНАШЕВО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

Р Е Ш Е Н И Е　　　　　　　　　　К А Р А Р

22 01.2025 года　　　　　　　　　　№ 143

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Советының
2024 елның 17 июнендәге 123 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы " Монашево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советының 2024 елның 17 июнендәге 123 номерлы “Җир салымы турында” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 пунктның 2 абзацында "әгәр әлеге пунктта башкасы каралмаган булса"сүзләрен өстәргә.

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Элек исәпләнгән салым суммасын яңадан исәпләү нәтиҗәләре буенча исәпләп чыгарылган салым салым түләүчеләр - физик затлар тарафыннан өченче айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча, шушы яңадан исәпләүгә бәйле рәвештә салым хәбәрнамәсе төзелгән айдан соң килүче айда түләнергә тиеш.";

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru "Монашево авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советының финанс - бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Советы рәисе　　　　　　Р.Ф.Иосифов